**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 236 от 01.09.2026

**Апас муниципаль районы муниципаль учреждениеларын булдыру, үзгәртеп кору, төрен үзгәртү һәм бетерү, шулай ук Апас муниципаль районы муниципаль учреждениеларының уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль канун нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р к ы л а:

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2026 елның 2 июнендәге 129 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль учреждениеләрен булдыру, үзгәртеп кору, төрен үзгәртү һәм бетерү, шулай ук Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль учреждениеләренең уставларын раслау һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибенә, аны 27.4 пункты белән тулыландырып, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«27.4. Мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы муниципаль оешмасының эшчәнлеге туктатылган очракта, «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе балигъ булган укучыларны — аларның ризалыгы белән, ә балигъ булмаган укучыларны — аларның ата-аналары (канунлы вәкилләре) ризалыгы белән, тиешле дәрәҗәдәге һәм юнәлештәге белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы башка оешмаларга күчерүне тәэмин итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесенә йөкләргә.

**Җитәкче** **Б.Н. Әхмәтҗанов**